ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

02.04.2024 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48. 04

пос. Октябрьский

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылында гражданнар җыенын
билгеләү турында 25.11.2023 ел №4 гражданнар җыены карарына
үзгәрешләр кертү мәсьәләсе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү 22.11.2013 ел № 90 тәртибенең 2 пункты (29.11.2023 ел № 1532 редакциясендә) нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. «Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылында гражданнар җыенының 2023 елның 25 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 12 апреленә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авылы җирлегенең Ключищи авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 25 октябрендәге 4 номерлы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авылы җирлегенең Ключищи авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге

эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

– торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(авыл эчендәге юлларны чокырлы ремонтлау)

коеларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү; су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су күтәрү манарасын урнаштыру)

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Ключищи авылы, Колхоз урамы, 95 йорт адресы буенча 10.00 сәгатьтә кибет бинасы янында гражданнар җыенын үткәрергә
4. Октябрьский авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш. Р. Азизов